**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.05.2018 № 377

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты
каршындагы яшьләр эшләре буенча Координацион
Совет Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында

Нурлат муниципаль районы территориясендә дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан, балалар һәм яшьләр оешмалары, берләшмәләре эшчәнлегенә кагылышлы сораулар буенча тәкъдимнәр эшләү, аларның дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлеге, Нурлат муниципаль районында яшьләр мәсьәләләрен хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү, «Россия Федерациясенең Җәмәгать палатасы турында" 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ Федераль законның 7 нче матдәсенә таянып, «Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында" 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ Федераль законның 4 нче матдәсенең 13 өлешенә нигезләнеп

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының "Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы яшьләр эшләре буенча Координацион Советы турында" 2018 елның 29 январе 74 нче боерыгы белән расланган Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы яшьләр эшләре буенча Координацион Совет Нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 пункттагы 4.6 пунктчасы 3 нче бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4.6. Яшьләр Координацион Советының әгъзалары булып:

- суд тарафынан эшкә яраксыз яки өлешчә яраклы дип табылган затлар;
- хөкем җәзасы тулысынча үтәлмәгән затлар;
- берүк вакытта ике ил гражданины булып саналган затлар;
- Җәмәгать палатасы әгъзасы булуы «Россия Федерациясе Җәмәгать палатасы турында» 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ Федераль законының 15 матдәсе 6нчы пункты 1 өлеше нигезендә алдан ук туктатылган затлар санала алмый". Бу очракта Җәмәгать палатасы әгъзасы булуга киртә булу түбәндәге төзелешле Җәмәгать палатасы эшчәнлегенә генә карый:

- Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе төбәкләрендә дәүләт вазифаларын вакытлыча үтәүче һәм муниципаль вазыйфалар һәм муниципаль хезмәтнең вазыйфаларын вакытлыча башкаручы затларга”.

Җитәкче А.С. Әхмәтшин